РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БОЛЬШЕАТРЯССКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ӘТРӘЧ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422378 с. Большие Атряси, ул. Гумара, 66

422378 Зур Әтрәч авылы, Гүмәр урамы, 66

тел. (84373) 58-3-05, факс 58-3-05, e-mail: Batr.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606557059, ИНН/КПП 1638001491/163801001

# КАРАР

**2019 елның 6 марты** **№ 41-1**

## 2014 елның 7 ноябрендәге 51-1 номерлы “Физик затлар милкенә салым турында”гы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 нче бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Зур Әтрәч авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2014 елның 7 ноябрендәге 51-1 номерлы “Физик затлар милкенә салым турында”гы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктта:

1.1.1. 2 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

“фатир өлешләрен.”;

1.1.2. 3 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

“торак йортларның бер өлеше.”.

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 3 нче пункт өстәргә:

“3. Ташлама ике фатирдан яисә фатир өлешеннән торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирларның яисә өлешләренең милекчеләренә исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрына яки

фатирның бер өлешенә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган сумга киметү рәвешендә бирелә.

Әгәр фатир яки фатирның бер өлеше гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга яки фатирның бер өлешенә милек хокукында аның өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Фатир яки фатирның бер өлеше уртак милектә булса, ташлама суммасы уртак милекнең һәр катнашучысына тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламаның суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аны исәпкә алмыйча артып китә алмый.”.

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 4 нче пункт өстәргә:

“4. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә:

4.1.1 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар;

4.2.1 әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары.”.

1.4. Түбәндәге эчтәлекле 4.1 нче пункт өстәргә:

“4.1. Әлеге карарның 4.1.1 һәм 4.1.2 пунктчаларында күрсәтелгән ташламалар эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган бер салым салу объектына карата бирелә дип билгеләргә:

1) фатирлар, фатир яки бүлмә өлешләре;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

3) гараж яисә машина урыны.”.

1.5. Түбәндәге эчтәлекле 5 нче пункт өстәргә:

“5. Салым ташламасына шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексында каралган башка категория салым түләүчеләрнең дә хокукы бар.”.

1.6. 3, 4 нче пунктларны 6, 7 нче пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карар үз гамәлен 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Әтрәч авыл җирлеге башлыгы** **И.Ш. Юнысов**